РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТА РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

| **РЕШЕНИЕ** | Буа шәһәре | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 05.05.2026 | | №1-11 |

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлегенең Боерган тимер юл разъезды поселогы торак пунктын бетерү турында

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлегенең Боерган тимер юл разъезды поселогын бетерергә.
2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлегенең Боерган тимер юл разъезды поселогын бетерү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы проектын караганда Буа муниципаль районы Советы вәкиле итеп Камартдинов Ранис Рафис улын – Буа муниципаль районы башлыгын билгеләп куярга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Камартдинов